| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2021 Казан ш. № 446-125/кс-2021

«Коммунальные сети – Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 № 254-87/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2022-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2023 елларга «Коммунальные сети – Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 №254-87/кс-2020 карарына 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 № 254-87/кс-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.12.2021 № 446-125/кс-2021 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

2021-2023 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы
«Коммунальные сети – Татарстан» ҖЧҖ өчен эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр |
| | Тукай муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Коммунальные сети – Татарстан» ҖЧҖ* (Әҗмәкәй авыл җирлеге Әҗмәкәй авылының «Подсолнухи» микрорайонындагы кулланучылар) | 34,97 | 36,28 | 35,49 | 35,49 | 35,49 | 38,03 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге